Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге составына керүче Акбаш торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ НӘТИҖӘЛӘРЕ ТУРЫНДА КАРАР**

«19» ноябрь 2025 ел №1

2025 елның 20 мартындагы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 33-ФЗ санлы Федераль законның 45, 69 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Уставының 26 маддәсе, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегенең Акбаш торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2025 елның 19 ноябрендә узган гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегенең Акбаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (ире (иптәше), ата-анасы), Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 2026 елда 500(биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә ризамы:

- Акбаш торак пунктында каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү (контейнер мәйданчыкларын төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, эш өчен килешү буенча түләү);
- Акбаш торак пунктында торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (грейдерлау, юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү) - соравы чыгарыла.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә: җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 300 граждан кертелде;

тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 156 кеше, бу 52% тәшкил итә.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленгән:

«За» позициясе өчен 156 граждан тавыш бирде;

«Каршы " позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены түбәндәгеләрне хәл итте:

1. Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегенең Акбаш торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын узган дип һәм аның нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегенең Акбаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (ире (иптәше), ата-анасы), Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 2026 елда 500(биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә ризамы:

- Акбаш торак пунктында каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү (контейнер мәйданчыкларын төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, эш өчен килешү буенча түләү);

- Акбаш торак пунктында торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (грейдерлау, юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү) – соравын кабул ителгән дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә(http://jutaza.tatarstan.ru.), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Акбаш авыл җирлеге башлыгы И.Р.Сәхибуллина